| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.05.2017 Казан шәһәре № под-812/17

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары өчен «Иң яхшы укытучы» гранты турында

Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмалары педагогик хезмәткәрләренең һөнәри осталык һәм иҗади активлык үсешен стимуллаштыру максатларында б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары өчен «Иң яхшы укытучы» грантын гамәлгә кую.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары өчен 2017 елның 13 июненнән 30 июненә кадәр «Иң яхшы укытучы» грантын алуга конкурс (алга таба – Конкурс) оештырырга һәм үткәрергә.

3. Расларга кушымта итеп бирелә торган:

3.1. Татарстан мәгариф һәм фән министрлыг карамагындагы һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары өчен «Иң яхшы укытучы» грантын (алга таба-«Иң яхшы укытучы» гранты») алуга конкурсны оештыру һәм үткәрү календарь планын;

3.2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары өчен «Иң яхшы укытучы» гранты турында Положениене.

4. «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә (Р.Р.Бәдриевага) Конкурсны оешыру - методик яктан тәэмин итәргә.

5. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г.Ф.Гатиятуллинага) Конкурсны оештыру һәм үткәрүгә бәйле булган чараларны финанслау эшен оештырырга.

6. Урта һөнәри белем бирүне үстерү бүлегенә (А.В.Сидоренкога) боерык кабул ителгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта, аны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

7. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А. И. Поминовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр урынбасары– министр Э.Н.Фәттәхов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән Министрлыгы
10.05.2017ел № под-812/17
боерыгы белән

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары өчен «Иң яхшы укытучы» грантын алуга конкурсны оештыру һәм үткәрүнең
календарь планы

| № п/п | Чара | Үтәлеш вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | "Иң яхшы укытучы» грантын алуга конкурс оештыру һәм үткәрү мәсьәләсе буенча Республика конкурс комиссиясе киңәшмәсе (алга таба - Конкурс) | 2017 елның май ае | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 2 | Һөнәри белем бирү оешмаларының укыту эшләре буенча директор урынбасарлары белән киңәшмә | 2017 елның май ае | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, “Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты” өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (алга таба - «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ») |
| 3 | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе сайтларында конкурс турында норматив-методик материалларны урнаштыру. | 2017 елның июне | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты » |
| 4 | Һөнәри белем бирү оешмалары базасында конкурсның беренче этабы | 2017 елның 13-14 июне | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри белем бирү оешмалары |
| 5 | Конкурсның республика этапларында | 2017 | ТР Мәгарифне үстерү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | катнашу өчен Грантка дәгъва кылучыларның гаризаларын җыю | елның 15-16 июне | институты» |
| 6 | Конкурсның өченче республика (турыдан-туры) этабын уздыру форматы турында мәгълүматны бастырып чыгару | 2017 елның 16 июне | ТР Мәгарифне үстерү институты» |
| 7 | Конкурска тәкъдим ителгән материалларга эксперт бәяләмәсе (икенче республика этабы) | 2017 елның 19-20 июне | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты |
| 8 | Өченче республика (турыдан туры) конкурс этабына катнашу өчен грантка дәгъва кылучылар исемлеген бастырып чыгару | 2017 елның 20 июне | ТР Мәгарифне үстерү институты» |
| 9 | Апелляцияләрне кабул итү һәм карау | 2017 елның 21-23 июне | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы,, ТР Мәгарифне үстерү институты |
| 10 | Конкурсның өченче республика (турыдан-туры) этабы | 2017 елның 26-28 июне | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы,, " ТР Мәгарифне үстерү институты |
| 11 | Грант алучылар исемлеген формалаштыру | 2017 елның 29 июне | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы,, Республика конкурс комиссиясе |
| 12 | Грант алучыларның расланган исемлеген Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм "«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты" сайтларында урнаштыру | 2017 елның 30 июне | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе» |

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән Министрлыгы
10.05.2017ел № под-812/17
боерыгы белән

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары өчен «Иң яхшы укытучы» гранты турында Положение (нигезләмә)**

1. Гомуми положениеләр

1.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары өчен «Иң яхшы укытучы» гранты (Алга таба - Грант) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә оештырыла.

1.2. Чарада катнашучылар булып грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) һәм грант алучы тора.

Грант бирүче- грантлар бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба –Министрлык).

Грантка дәгъва кылучы – Татарстан Республикасы мәгариф һәм министрлыгы карамагындагы һөнәри белем бирү оешмасының штат хезмәткәре, ул- әлеге вазифа буенча гариза биргән вакытта, өч елдан да ким булмаган эш стажы булган педагогик хезмәткәр (гомуми белем бирү, гуманитар, табигый-фәнни, гомумпрофессиональ дисциплиналар, дисциплинарара курслар укытучысы).

Грант алучы - Татарстан Республикасы мәгариф һәм министрлыгына караган һөнәри белем бирү оешмасы хезмәткәре, ул- әлеге положениедә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган, конкурс сайлап алуы узган һәм гомуми белем бирү, гуманитар,табигый-фәнни дисциплиналар арасында рейтингта 1-15 урын алган (15 грант алучы), яки дисциплинарара курсларның гомумпрофессиональ дисциплиналар укытучылары арасында 1-35 урын алган (35 грант алучы) педагогик хезмәткәр.

Грант алучыларга ай саен хезмәт хакына өстәп түләнә торган 8 046 (сигез мең кырык алты) сум күләмендәге өстәмә акча Грант булып тора.

1.2. Грант алуга Конкурс (алга таба - Конкурс) Татарстан Республикасы мәгариф һәм министрлыгына тарафыннан «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба - Т Р Мәгарифне үстерү институты) белән берлектә педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын һәм иҗади активлыгын үстерүне стимуллаштыру максатларында үткәрелә.

1.3. Конкурсның максаты:

Һөнәри белем бирү оешмаларының сәләтле укытучыларын ачыклау һәм ярдәм итү;

укытучыларның иҗади башлангычларын, аларның киләчәк интеллектуаль үсешен мотивацияләү һәм стимуллаштыру;

«укытучы» һөнәренең абруен күтәрү;

укытучыларны Татарстан Республикасының һөнәри белем бирүне модернизацияләүнең инновацион проектларына җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру;

нәтиҗәле педагогик тәҗрибәне пропагандалау һәм тарату.

1.4. Конкурс түбәндәге этаплардан тора:

1.4.1. 2017 елның 13 июненнән 14 июненә кадәр һөнәри белем бирү оешмасы дәрәҗәсендә Конкурсның беренче этабы;

1.4.2. 2017 елның 19 июненнән 20 июненә кадәр Конкурсның икенче республика (читтән торып сайлау) этабы;

1.4.3. 2017 елның 26июньнән 28 июньгә кадәр Конкурсның өченче Республика (турыдан - туры) этабы.

## 2. Конкурсны оештыру

2.1. Конкурсны оештыру-методик яктан тәэмин итү һәм үткәрүне:

2.1.1. һөнәри белем бирү оешмасы базасында узачак конкурсның беренче этабында һөнәри белем бирү оешмасы тарафыннан формалаштырылган беренче этапның конкурс комиссиясе;

2.1.2. Конкурсның икенче республика (читтән торып) этабында һәм конкурсның өченче республика (турыдан - туры) этабында конкурсны әзерләү һәм

үткәрүне рәис, җаваплы сәркатип һәм комиссия әгъзалары составындагы Республика конкурс комиссиясе башкара.

2.1.3. Республика конкурс комиссиясенең персональ составы Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана. Республика конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның составының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала.

2.1.4. Республика конкурс комиссиясе: ;

конкурсны үткәрүне әлеге Нигезләмә нигезендә оештыра;

экспертлар составын сайлап алуны гамәлгә ашыра;

һөнәри белем бирү оешмалары тарафыннан бирелә торган Грантка дәгъва кылучыларның конкурс материалларын (билгеләнгән форма буенча) кабул итә;

конкурсны үткәрүнең оештыру-техник шартларын тәэмин итә;

конкурска йомгак ясый һәм массакүләм мәгълүмат чараларына, педагогик җәмәгатьчелеккә аның нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

2.1.5. Конкурсның икенче Республика (читтән торып) этабын үткәрү нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, Грантка дәгъва кылучы Республика конкурс комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында Грантка дәгъва кылучыларны конкурсның икенче этабына чыгару турында Республика конкурс комиссиясе карары басылып чыккан көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта, электрон почта аша master/tatarstan@mail/ru адресына ирекле язма формада Республика конкурс комиссиясе рәисе исеменә бирелә.

2.1.6. Апелляцияне Республика конкурс комиссиясе ,апелляция бирү вакыты тәмамланганнан соң, бер эш көне эчендә карый. Республика конкурс комиссиясе, конкурс материалларын бәяләгәндә, Эксперт комиссиясе тарафыннан хокук бозулар булган-булмаганны билгели, шулай ук ул бәяләү балларын аргументацияләү өчен экспертларны чакыру хокукына да ия.

Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча Республика конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен чыгара:

апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклап калу турында;

апелляцияләрне канәгатьләндерү, Грантка дәгъва кылучыны өченче (турыдан-туры) республика этабына чыгару һәм грант алучыны республика этабының өченче (турыдан-туры) катнашучылары исемлегенә кертү турында.

Апелляция буенча Республика конкурс комиссиясе карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, республика конкурс комиссиясе рәисе хәлиткеч тавыш бирергә хокуклы.

2.2. Конкурсның икенче республика этабы конкурс материалларын һәм өченче республика этабының конкурс биремен бәяләү өчен , составында рәис һәм комиссия әгъзалары булган Эксперт комиссиясе төзелә.

2.2.1. Эксперт комиссиясенең персональ составы Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

2.1.2. Конкурс материалларын һәм конкурс биремнәрен экспертизалау вакытында, Эксперт комиссиясе эшенә бәйсез экспертлар җәлеп ителә ала.

2.2.3. Конкурсның икенче республика (читтән торып) этабындагы

конкурс материалларына экспертиза үткәргәндә, катгый рәвештә бәяләү критерийлары нигезендә, тәкъдим ителгән материалларны бәяләүнең объективлыгы тәэмин ителә.

2.2.4. Конкурсның өченче республика (турыдан-туры) этабында катнашучыларны бәяләү эксперт комиссиясе әгъзалары тарафыннан, катгый бәяләү критерийлары нигезендә, эксперт бәяләве методы белән гамәлгә ашырыла.

2.3. Эксперт комиссиясе:

билгеләнгән вакытка, әлеге положениедә билгеләнгән критерийлар нигезендә, Конкурсның Республика (читтән торып һәм турыдан-туры) этапларында Грантка дәгъва кылучыларның конкурс материалларын һәм конкурс биремен бәяли ;

эксперт имзасы белән расланган эксперт битләренә баллар кертә һәм эксперт комиссиясе рәисенә тапшыра;

эксперт битләре нигезендә Грантка дәгъва кылучыларның рейтингын формалаштыра. Эксперт комиссиясе рәисе кул куйган Рейтинг Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

Эксперт комиссиясенең икенче республика (читтән торып) этабындагы эше нәтиҗәләре буенча, конкурсның өченче республика (турыдан-туры) этабында катнашу өчен, Грантка дәгъва кылучыларның исемлеге төзелә һәм раслана.

Эксперт комиссиясенең өченче Республика (турыдан-туры) этабындагы эше нәтиҗәләре буенча йомгаклау рейтингы һәм Грант алучылар исемлеге төзелә һәм раслана.

## 3. Конкурсны үткәрү

3.1. Конкурс Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә үткәрелә.

3.2 Грант бирүче Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм “Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты” өстәмдә һөнәри белем бирүче дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең рәсми сайтларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән конкурс үткәрү турында игълан итә.

3.3. Конкурс өч этапта үткәрелә.

3.3.1. Конкурсның беренче этабы һөнәри белем бирү оешмасы дәрәҗәсендә Грантка дәгъва кылучыларның портфолиоларын тәкъдир итү рәвешендә үткәрелә.

3.3.2. Портфолио компьютер презентациясе форматында (POVER POINT), Грантка дәгъва кылучының педагогик һәм һөнәри тәҗрибәсен , соңгы ике уку елындагы казанышларын, шулай ук югары квалификацияле белгечләр әзерләүне камилләштерүгә юнәлдерелгән методикалар һәм технологияләрне чагылдыра торган 20 слайд күләменә кадәрле зурлыктагы тасвирламасында булырга тиеш.

3.3.3. Беренче этап нәтиҗәләре буенча һөнәри белем бирү оешмасы өч призерны (ике гомумпрофессиональ дисциплина һәм дисциплинарара курслар укытучысын, бер гомуми белем бирү, гуманитар һәм табигый-фәнни дисциплиналар укытучысын) билгели.

Һөнәри белем бирү оешмасы Конкурсның беренче этабы нәтиҗәләрен конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерә. Конкурсның алдагы этапларында катнашу өчен, Грантка дәгъва кылучылар тарафыннан, әлеге Положение нигезендә, конкурс материаллары әзерләнә.

3.4. Конкурсның икенче республика (читтән торып) этабында (алга таба - конкурсның читтән торып катнашу этабы) катнашырга, Конкурсның беренче һөнәри белем бирү оешмасы дәрәҗәсендәге этабының өч призеры (ике гомумпрофессиональ дисциплина һәм дисциплинарара курслар укытучысы, бер гомуми белем бирү, гуманитар һәм табигый-фәнни дисциплиналар укытучысы) чакырыла.

3.4.1. 2017 елның 16 июненнән дә соңга калмыйча, һөнәри белем бирү оешмасының җаваплы вәкилләре (җитәкче урынбасары, методист) тарафыннан электрон почта аша түбәндәге адреска :(master.tatarstan@mail.ru) (элемтә өчен җаваплы зат - Митрофанова Эльвира Павловна, ӨҺББ ДАМУ«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты "ның һөнәри белем бирү стандартлары һәм технологияләре лабораториясе мөдире, тел. (843) 236-65-82) Конкурсның читтән торып үткәрелгән этабында катнашу өчен гариза җибәрелә.

3.4.2. ӨҺББ ДАМУ «ТР Мәгарифне үстерү институты» грантка дәгъва кылучылар буенча җибәрелгән гаризалар нигезендә мәгълүмат җыентыгын булдыра.

3.4.3. Гариза 2017 елның 16 июненнән дә соң тапшырылган очракта, грантка дәгъва кылучы конкурста катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

3.5. Конкурсның читтән торып катнашу этабы республика дәрәҗәсендә, билгеләнгән график нигезендә, 2017 елның 19-20 июнендә конкурс материалларына Эксперт комиссиясе тарафыннан экспертиза үткәрү формасында үткәрелә.

Эксперт комиссиясе утырышының графигы һәм урыны Республика конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Конкурс материаллары эксперт комиссиясе утырышында һөнәри белем бирү оешмасының җаваплы вәкиле (җитәкче урынбасары, методист) тарафыннан билгеләнгән график нигезендә тәкъдим ителә. Эксперт комиссиясенә, конкурс материалларыннан тыш, грантка дәгъва кылучының педагогик эшчәнлеге нәтиҗәлелеген раслаучы документларның оригиналлары тәкъдим ителергә тиеш.

Конкурсның икенче этабына тәкъдим ителә торган материаллар исемлеге:

конкурста катнашу өчен, грантка дәгъва кылучының гаризасы;

грантка дәгъва кылучның анкетасы;

һөнәри белем бирү оешмасының Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе (конкурсның беренче этабы));

һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенең грантка дәгъва кылучыны тәкъдим итүе, анда катнашучының тәкъдим ителүен кыскача нигезләү (соңгы 2 уку елында укытучының һөнәри эшчәнлектәге уңышлары,казанышлары, укытыла торган дисциплиналарның эчтәлегенә һөнәри стандартлар, Ворлдскиллс халыкара стандартлары таләпләре курсларын кертү эше, укучыларны һөнәри осталык конкурсларына һәм һөнәри сыйфатларын, күнекмәләрен, компетенцияләрен үстерергә ярдәм итүче башка конкурсларга әзерләүдә катнашу, укытучының һөнәри осталык конкурсларда катнашуы,һөнәри белем бирү оешмасы бланкысында төзелгән, аның җитәкчесе тарафыннан расланган алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү (3 (өч) биттән артык булмаган). Тәкъдим итүгә раслаучы документларның күчермәләре куела;

грантка дәгъва кылучының педагогик эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесе урынбасарының бәяләмәсе (укучыларның соңгы 2 уку елындагыгы төп уңышлары һәм казанышлары: һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесе урынбасары тарафыннан расланган һөнәри осталык конкурсларында катнашучылар һәм призерлар, шул исәптән Ворлдскиллс стандартлары буенча чемпионатлар, фәнни-тикшеренү һәм иҗади эшләр конкурслары, фән олимпиадалары, башка конкурсларда һ.б.) (3 (өч) биттән артык булмаган). Бәяләмәгә раслаучы документларның күчермәләре куела;

тиешле компетенция буенча махсуслаштырылган компетенцияләр үзәгенең (алга таба - МКҮ) баш экспертының грантка дәгъва кылучының ярышларда катнашучыларны әзерләүдә һәм/яки Ворлдскиллс ярышларын уздыруда катнашуы турында, Ворлдскиллс стандартларын исәпкә алып, Дәүләт имтихан комиссиясе әгъзасы, Ворлдскиллс стандартларын исәпкә алып, дәүләт йомгаклау аттестациясен уздырганда күзәтүче ролендә катнашуы турында бәяләмә (әлеге чараларда грантка дәгъва кылучының катнашу шарты белән).

ике елга шәхси һөнәри үсеш программасы (ирекле формада, 3 биттән дә артык түгел.);

грантка дәгъва кылучы укыта торган дисциплина/ дисциплинаара курсның бер темасы буенча укучының белемнәрен, белем һәм күнекмәләрен, эшчәнлекнең конкрет төре белән турыдан-туры бәйле рәвештә үз-үзен тотуының нәтиҗәле модельләрен үстерергә мөмкинлек бирә торган кейс биреме методик эшкәртмәсе. Кейс биремне чишү, проблеманы хәл итүнең альтернатив юлларын билгеләү белән, иң нәтиҗәле карарны гамәлгә ашыру буенча чаралар планы тасвирламасында (10 биттән артык түгел) бирелә;

профессиональ стандартлары һәм Ворлдскиллс стандартлары таләпләрен дисциплина (модуль) эчтәлегенә кертүне анализлау яки гомуми белем бирү дисциплинасы эчтәлегенең һөнәри юнәлешлелеген анализлау (5 биттән артык түгел).

Республика конкурс комиссиясенә кергән грантка дәгъва кылучыларның материаллары кире кайтарылмый һәм рецензияләнми.

Материаллар электрон һәм басма вариантта *(а-4) шрифт - 14 Times New Roman, интервал 1,0. форматында бирелә.

Билгеләнгән таләпләрне бозып әзерләнгән һәм графикта күрсәтелгән сроктан соңрак кергән материаллар кабул ителми.

Һөнәри белем бирү оешмасы тәкъдим ителгән грантка дәъва кылучыларның материалларының дөреслеге, сыйфаты өчен җавап бирә.

3.5.1.Конкурсның читтән торып катнашу этабы нәтиҗәләре буенча эксперт комиссиясе тарафыннан эксперт комиссиясе Карары төзелә, ул беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм 2017 елның 20 июненнән дә соңга калмыйча, Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

3.6. Конкурсның өченче республика (турыдан - туры) этабы (алга таба- конкурсның турыдан-туры этабы) 2017 елның 26-28 июнендә грантка дәъва кылучының һөнәри һәм педагогик тәҗрибәсен тәкъдир итү рәвешендә үткәрелә.

Конкурсның турыдан-туры этабында катнашу өчен, гомуми белем бирү, гуманитар, табигый-фәнни дисциплиналар укытучылары арасыннан, буенча

рейтингта 1-23 урыннарга чыккан грантка дәъва кылучылар һәм гомумпрофессиональ дисциплиналар һәм дисциплинарара курслар укытучылары арасыннан рейтингта 1дән 53 урыннарга чыккан грантка дәъва кылучылар чакырыла.

Презентация форматы һәм чыгыш регламенты Республика конкурс комиссиясе тарафыннан раслана.

Конкурсның турыдан-туры этабында катнашучыларга презентация форматы һәм чыгыш регламенты турында хәбәр итү ,2017 елның 16 июненнән дә соңга калмыйча, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең рәсми сайтында мәгълүмат бастырып чыгару юлы белән гамәлгә ашырыла.

Конкурсның көндезге этабын үткәрү графигы һәм урыны Республика конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә

3.6.1. Конкурсның турыдан-туры этабы йомгаклары буенча Эксперт комиссиясе карары төзелә, ул беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм 2017 елның 28 июненнән дә соңга калмыйча, Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

## 4. Грантка дәъва кылучыларның конкурс материалларын һәм конкурс биремен бәяләү

4.1. Конкурсның беренче этабы материаллары түбәндәге күрсәткечләр нигезендә балл системасы буенча конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләнә:

| Күрсәткеч атамасы | Бәяләү критерийлары | Балларда бәя |
|---|---|---|
| Тәкъдим ителгән тәҗрибәнең актуальлеге һәм яңалыгы | тәкъдим ителгән тәҗрибәнең актуальлеге һәм яңалыгы, педагогик эшчәнлекнең белем бирү процессында җитештерү укытуын һәм һөнәри иҗатны камилләштерүгә юнәлдерелгән булуын трансляцияләү мөмкинлеге. | 0-15 |
| Эшчәнлек нәтиҗәлелеге | һөнәри осталык конкурсларында призлы урыннар булу; региональ инновацион мәйданчык | 0-15 |

| | | |
|---|---|---|
| | эшчәнлегендә катнашу; Ворлдскиллс стандартлары буенча чемпионатта катнашучылар һәм призерлар арасыннан укучылар саны; конкурс һәм олимпиадаларда, фәнни-тикшеренү һәм иҗади конкурсларда җиңүчеләр арасыннан укучылар саны | |
| Тамашаның бөтенлеге һәм системалылыгы | слайдларда мәгълүмат бирү культурасы; бирелгән мәгълүматның логик эзлеклелеге, бизәлешнең дөреслеге һәм сыйфаты. | 0-10 |

4.1.1. Баллар һәр критерий буенча исәпләнә һәм кушыла. Конкурсның беренче этабында катнашучы ала торган максималь баллар саны-40. Грант Грантка дәъва кылучыларның  балларның суммар күрсәткече киму тәртибендә рейтингта урнаша.

4.2. Конкурсның читтән торып үткәрелгән этабы материалларының эчтәлеге эксперт комиссиясе тарафыннан балл системасы буенча түбәндәге күрсәткечләр нигезендә бәяләнә:

| Күрсәткеч атамасы | Конкурска тәкъдим ителгән материаллар төре | Бәяләү критерийлары | Балларда бәя |
|---|---|---|---|
| Нәтиҗәлелек | Тәкъдим итүе | һөнәри үсеш | 0-9 |
| һөнәри эшчәнлек (0-30 балл) | Грантка дәгъва кылучыны һөнәри белем бирү оешмасыеың җитәкчесе тарафыннан | укытучының компетентлыгы (профессиональ конкурсларда, күргәзмәләрдә,конференцияләрдә катнашуы); | |
| | | журналларда басылып чыккан уку һәм методик әсбаплар, рекомендацияләр булу | 0-4 |
| | | Ворлдскиллс стандартлары буенча чемпионатларда катнашу өчен укучыларны әзерләү; | 0-4 |
| | | Ворлдскиллс | 0-4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | стандартлары буенча компетенцияләр (һөнәрләр) буенча республика экспертының статусы булу; | |
| | | квалификацияле кадрлар әзерләү буенча эшчәнлек нәтиҗәләре (һөнәри осталык конкурслары, һөнәри юнәлеш бирү буенча чаралар оештыру һәм үткәрү.); | 0-4 |
| | | тәрбия һәм социаль юнәлешле педагогик проектларны эшләү һәм тормышка ашыру; | 0-4 |
| | | региональ инновацион мәйданчык (алга таба - РИМ) эшчәнлегендә катнашу турында документлар булу | 0 документлар булмау 2 документлар булу |
| Педагогик эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге (0-30 балл) | һөнәри белем бирү оешмасының җитәкче урынбасарының Грантка дәгъва кылучының педагогик эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында турында бәяләмәсе | Ворлдскиллс стандартлары буенча чемпионатларда катнашучылар һәм призерлар арасыннан укучылар булу; | катнашучылар булу - 4<br>катнашучылар һәм призерлар -20 |
| | | Республика, федераль һәм халыкара дәрәҗәдәге конкурслары һәм олимпиадалары, фәнни-тикшеренү һәм иҗат конкурсларында җиңүчеләр һәм призерлар арасыннан | республика дәрәҗәсендә - 4<br>федераль һәм халыкара дәрәҗәдәге-6<br>барлык дәрәҗәдәге-10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | укучылар булу<br>. | |
| Ворлдскиллс хәрәкәте кысаларында педагогик эшчәнлек нәтиҗәләре (0-10 балл | махсуслаштырылган компетенцияләр үзәгенең баш эксперт/күзәтүчесен бәяләмәсе (Ворлдскиллс хәрәкәтендә грантка дәгъва кылучының катнашуы шарты белән) | Ворлдскиллс ярышларда катнашучыларның грантка дәгъва кылучы тарафыннан югары әзерлек дәрәҗәсе;<br><br>Ворлдскиллс чемпионатларын үткәргәндә грантка әгъва кылучының компетентлыгының югары дәрәҗәдә булуы;<br><br>Ворлдскиллс ярышларын уздырган вакытта күзәтүче сыйфатында актив катнашу; | 0-2<br><br>0-3<br><br>0-3 |
| | | грантка әгъва кылучының Дәүләт имтихан комиссиясе әгъзасы сыйфатында актив катнашуы | 0-2 |
| Планлаштыру һөнәри үсеш (0-5 балл) | Шәхси һөнәри үсеш программасы | үз һөнәри үсешен перспективалы планлаштыру дәрәҗәсе;<br><br>компетентлык кытлыгын билгели белү, эшчәнлек перспективаларының һөнәри каршылыкларны диагностикалау | 0-2<br><br>0-3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | уздыру; | |
| Кейс биремен эшләү (0-10 балл) | Кейс биременен методик эшкәртмәсе | Кейс бирemenең юнәлешлелек дәрәҗәсе;<br><br>Кейс биремнәрен эшләнеш дәрәҗәсе, проблемалар булу;<br><br>альтернатив карарлар булуы;<br><br>Кейс презентациясен һәм әңгәмә алып бару өчен укучылар өчен сораулар һәм биремнәрнең булуы. | 0-3<br><br>0-3<br><br>0-2<br><br>0-2 |
| профессиональ стандартлар һәм Ворлдскиллс стандартлары таләпләрен гамәлгә кертү/ гомуми белем бирү дисциплиналарының эчтәлегенә профессиональ юнәлеш бирү (0-15 балл) | профессиональ стандартлары һәм Ворлдскиллс стандартлары таләпләрен дисциплина (модуль)эчтәлегенә кертү яки гомуми белем бирү дисциплиналарының эчтәлегенә профессиональ юнәлеш бирү анализы | сайланган проблемага анализ эчтәлегенең туры килүе;<br><br>аналитик материалның информативлыгы дәрәҗәсе;<br><br>практик нәтиҗәләр булу;<br><br>анализның структурасы һәм логикасы, нәтиҗәләр булу. | 0-2<br><br>0-5<br><br>0-5<br><br>0-3 |

4.3. Конкурсның турыдан-туры этабы конкурс бирременең эчтәлеге эксперт комиссиясе тарафыннан балл системасы буенча түбәндәге күрсәткечләр нигезендә бәяләнә:

| Күрсәткеч атамасы | Бәяләү критерийлары | Балларда бәя |
|---|---|---|
| Бөтенлек | һөнәри һәм педагогик практика барлыкны бөтенләтә күз алдына китерә белү | 0-10 |
| Эчтәлек | производствога өйрәтү остасы эшенең үзенчәлеген ачарга мөмкинлек бирә торган чыгышның эчтәлеген формалаштыра белү;<br><br>практика белән бйләнеш | 0-7<br><br>0-3 |
| коммуникативлык | булган проблемаларны нәтиҗәле хәл итү юлларын һәм булган ресурсларны бәяләү белән булган кыенлыкларны җиңү юлларын күрү;<br><br>куелган максатларга һәм бурычларга ирешү, ирешелгән нәтиҗәләрне планлаштырылган нәтиҗәләр белән чагыштыру | 0-5<br><br>0-5 |
| Технологиялелек | тәкъдим ителгән технологияләрнең, алгоритмнарның, кабул итүнең тулылыгы һәм оптимальлеге | 0-5 |
| Әйләнеш трансляцияллəшүчәнлек | һөнәри эшчәнлекнең гамәли казанышларын тарату һәм куллану мөмкинлеге | 0-10 |
| Мәгълүмати һәм тел культурасы | төшенчәләр аппаратын һәм фәнни телне куллану корректлылыгы һәм дөреслеге, фактик хаталар булмау, теманы аңлау тирәнлеге һәм киңлеге;<br><br>мәгълүмат белән эшләү формаларының төрлелеге | 0-3<br><br>0-2 |

4.3.1. Баллар һәр критерий буенча исәпләнә һәм кушыла. Конкурсның читтән торып катнашу этабында катнашучы ала торган максималь баллар саны-50. Грантка

дәъва кылучылар балларның суммар күрсәткече кимү тәртибендә рейтингта урнаша.

## 5. Җиңүчеләрне игълан итү

5.1. 2017 елның 29 июнендә конкурсның турыдан-туры этабы йомгаклары буенча Республика конкурс комиссиясе грант алучылар исемлеген формалаштыра.

5.2. Конкурсның турыдан-туры этабында катнашучыларга «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе катнашу турында сертификатлар тапшырыла.

5.3. Грант бирүче 2017 елның 30 июнендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе сайтларында Грант алучыларның расланган исемлеген урнаштыра.

## 6. Грантны финанслау

Грант бирү максатларында субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Кушымта 1
Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгы карамагындагы
һөнәри белем бирү оешмалары
укытучылары өчен «Иң яхшы укытучы»
гранты турындагы положениегә

“Иң яхшы укытучы” грантын алуга конкурста катнашу өчен гариза

Белем бирү оешмасы (белем бирү оешмасының рәсми исемен күрсәтергә)____________________________________________________________

Мәгариф оешмасы җитәкчесе (Ф. И. О. тулысынча)_____________________

Телефон____________________________________________________________

(адрес, электрон почта)______________________________________________

Белем бирү оешмасының юридик адресы (почта индексын күрсәтеп))______________________________________________________________

Телефон___________________, факс______________________

Конкурста катнашу өчен түбәндәге гомуми белем бирү дисциплиналарының укытучыларын җибәрәбез

| № п/п | ФИО катнашучы | Әзерлек алып барыла торган дисциплина |
|---|---|---|
| 1. | | |
| 2. | | |

Конкурста катнашу өчен гуманитар, табигый-фәнни һәм гомумпрофессиональ дисциплиналар һәм дисциплинарара курсларның түбәндәге мөгаллимнәрен юллыйбыз

| № п/п | ФИО катнашучы | әзерлек барыла торган дисциплина/МД, |
|---|---|---|
| 1. | | |
| 2. | | |

Дата (сан; ай) 2018 ел.

___________ _____________

[Култамга] [вазыйфа] мәгариф оешмасы мөһере

Кушымта 2
Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгы карамагындагы
һөнәри белем бирү оешмалары
укытучылары өчен «Иң яхшы укытучы»
гранты турындагы положениегә

"Иң яхшы укытучы" грантын алуга конкурста катнашучы анкетасы

Конкурсантның исем-фамилиясе

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Педагогик эшчәнлек урыны ____________________________________

______________________________________________________________

Белем (белем бирү оешмасы, факультетын күрсәтеп) ______________

______________________________________________________________

Белгечлеге буенча диплом______________________________________

Мактаулы исемнәр (бүләкләр)___________________________________

Педагогик стажы____________ Әлеге вазыйфасы буенча стажы________________

Категория а) _______ бар б) _________________ дәгъвалыйм
Яшәү урыны ____________________ тел./сот.____________

Педагогик эшчәнлек алып барыла торган дисциплина

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Мәгълүмати (компьютер) технологияләргә ия булу: компьютер белән эш итә белмим, педагогик эшчәнлектә кулланам (тиешле басым ясарга кирәк))

Тутыру датасы « »______________ Шәхси имза____________________

Кушымта 3
Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгы карамагындагы
һөнәри белем бирү оешмалары
укытучылары өчен «Иң яхшы укытучы»
гранты турындагы положениегә

Кейс эшләүгә таләпләр

Кейс ( ингл. case study-тикшеренү, очрак анализы) - проблеманы нәтиҗәле хәл итү буенча анализ һәм тәкъдимнәр таләп итә, дискуссия китереп чыгара торган җайга салынган эш вәзгыяте. Бу билгеле бер проблеманы, һәрвакыт бердәм дөрес җавапка ия булмаган сорауны  үз эченә алган аерым алынган конкрет һөнәри ситуациянең җентекле тасвирламасы.

Кейс биременә таләпләр:

- кейс бирелмендәге мәгълүмат, кирәкле белемнәр һәм күнекмәләргә ия булган укучыга нигезле карар кабул итә һәм аны күрсәтә алыр өчен,  җитәрлек күләмдә булырга тиеш.
- ситуациянең язма тасвирламасы укучыларга проблеманы (проблемаларны) ачыкларга, тәкъдим ителгән мәгълүматны анализларга һәм, алар күзлегеннән караганда, иң нәтиҗәле хәл итү  юлын булдырга мөмкинчелек тудырырга тиеш.
- Кейста тәкъдим ителгән ситуациянең нең берничә чишелеше һәм аларга китерә торган күп кенә альтернатив юллары булырга тиеш;
- кейс укучылар өчен биремнәр һәм кейс презентациясен алып бару өчен мөмкин булган сораулардан торырга тиеш.
- Кейсны тикшерү нәтиҗәсендә студентлар әлеге ситуация буенча һәм ачыкланган проблеманы хәл итү юллары турында хисап (язма анализ) төзү һәм тапшыру, карарны тормышка ашыру буенча чаралар планын эшләү мөмкинлегенә ия булырга тиеш.